**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Альметьевского сельского поселения**
**Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы Әлмәт**
**авыл җирлеге башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2021ел, 14 май**

**КАРАР**
**№ 11**

Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 26 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 26 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган торглар үткәрмичә муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1.1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.2. 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип таныргa;
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 26 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлеген даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   2.1.1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
   2.2. 1 нче кушымта үз көчен югалткан дип таныргa;
3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 26 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген торг үткәрмичә арендага бирү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   3.1 1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
   3.2 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип таныргa;
4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 21 декабрендәге 15 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип таныргa.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — Д.Ә.Газизов.